СОВЕТ УРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

22.09.2026 ел № 1

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге Советы

# КАРАРЫ

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 августындагы «Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавәми тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» №1 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясендә Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсенең 8 өлеше һәм 31 маддәсенең 13 өлеше нигезендә (04.08.2026 елга үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 июлендәге «Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавәми тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» №2 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 12 маддәсенең 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлаулар үткәрү вакыты муниципаль берәмлекнең халкына аның үткәреләчәге турында хәбәр иткән көннән башлап, иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастырып чыгарганга кадәр, муниципаль берәмлекнең уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан артык була алмый. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышу яисә гавәми тыңлауларның дәвамлылыгы вакыты әлеге проектны бастырып чыгару көненнән башлап, бер айдан күбрәк була алмый.»

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе И.С.Аскюкова